Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

14 сентябрь, 2022 ел № 20

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге территориясендә комплексы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү комиссиясе турында» 20.07.2022 елның 20 июлендәге 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы, «Комплексы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урынын килештерү өчен төзелә торган килешү комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 20 мартындагы 177 номерлы карары, «Комплексы кадастр эшләрен оештыру турында»2020 елның 31 мартындагы 237 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең 2022 елның 29 августындагы 14-22@/23478-э номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитеты карар **кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге территориясендә комплексы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү комиссиясе турында» 20.07.2022 елның 20 июлендәге 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

1.1 әлеге карарның 1 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны Шәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җваплылыгымда калдырам.

Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль
районы Шәле авыл җирлеге башкарма
комитеты карары белән расланды
20 июль, 2022 ел № 16

2022 елда Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Әхмәтҗанов И.Р. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Абдуллин А.А. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары | |
| Дәүләтханов И.Р. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Шәйхетдинов Р.Р. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Беляков М.В. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге начальнигы |
| Рогожкин М.А. | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары |
| Фәсхетдинов Р.Р. | Дәүләт милке белән идарә итү буенча Федераль агентлыкның Татарстан Республикасында һәм Ульяновск өлкәсендә төбәкара территориаль идарәсе җитәкчесе урынбасары |
| Тиханова Э.А. | Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Питрәч һәм Балык Бистәсе районнары буенча муниципальара бүлек башлыгы |
| Хәбибрахманов Р.Р. | «ТР БТИ» АҖ техник директоры |
| Зиннатуллин Ф. А | «Алмагач» коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте рәисе |
| | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрлыгы (килешү буенча) |